| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КРАСНОБОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КРАСНЫЙ БОР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2018 Красный Бор авылы № 20

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге уставы белән, 2018 елның 28 августындагы 11 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Красный Бор авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Н. Лазарев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Красный Бор авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №20
белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү I группа инвалидлар, торып укучы студентлардан тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 30.03.2019 вакытка кадәр, аларның җирле референдумда катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

4. Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5.Гражданнарның үзара салымнан алынган акчалары Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең лицевой (шәхси)счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Красный Бор авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №20 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ___________________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________________
Нигезләмә ___________________________________________________________________
Сезгә ___________________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә ____________________
_______________________________чараны гамәлгә ашыру буенча ______ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК ________________________________________
Сч. № ________________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН ________________________________________
КПП ________________________________________
КБК _________________ ОКАТО ____________________
Түләүнең билгеләнеше ___________________________________________________________

Җитәкче ____________________ _____________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

_________________________________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне __________ сум күләмендә түләү турында № _________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ___________________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________________

Кабул ителде «__ __» ____________ 20__ ел. _____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм ________________ җирлеге башкарма комитетында кала.*